**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.06.2018 Балык Бистәсе штп. № 142пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 23 мартындагы 81пи номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәп) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы, Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, аларның типларын үзгәртү һәм бетерү тәртибен раслау, шулай ук Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре уставларын раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 12 декабрендәге 234пи номерлы карары нигезендә , Татарстан Республикасы Президенты Р. Н. Миңнехановның 26.03.2018 № вн-2136-МР һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры А. В. Песошинның 27.03.2018 № 16116-АП күрсәтмәләренә таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 23 мартындагы 81пи номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәп) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе Уставына (алга таба-Устав)кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2."Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәп) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директорына әлеге карар нигезендә Уставка кертелә торган үзгәрешләрне законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы буенча 18 нче номерлы Россия

Федераль салым хезмәте районара инспекциясендә дәүләт теркәвен үткәрүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны  Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте,спорт һәм туризм бүлеге”нә йөкләргә.

Җитәкченең беренче урынбасары Р.Л. Исланов

Татарстан республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2018 елның 26
июнендәге №142пи карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 23 мартындагы 81пи номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәп) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе Уставына**
**кертелә торган үзгәрешләр**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 23 мартындагы 81пи номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәп) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе Уставына (алга таба-Устав) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

түбәндәге эчтәлекле " Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм көйләү» 5.1 бүлеген өстәргә:

**«5.1. Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм көйләү**

5.1.1.Мәнфәгатьләр конфликты астында учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы аның хезмәт бурычларын тиешенчә үтәвенә тәэсир итә алган һәм анда учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм ул эшләгән учреждениенең мөлкәтенә һәм (яки) учреждениенең эшлекле абруена зыян китерергә сәләтле учреждениенең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында каршылык барлыкка килергә мөмкин булган хәл аңлашыла.

5.1.2.Хезмәт вазифаларын тиешенчә башкаруга йогынты ясаучы яисә тәэсир итә алучы учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы астында учреждение хезмәткәренең керемнәрне акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәти хокуклар яисә мөлкәти характердагы хезмәтләр рәвешендәге хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә алу мөмкинлеге аңлашыла.

5.1.3.Учреждение директоры эш бирүчене (гамәлгә куючыга) вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итәргә тиеш .

5.1.4.Учреждение хезмәткәре учреждение директорына вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш . Учреждение директорына хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдәге мәгълүматлар исемлеге, бу белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе учреждение директоры тарафыннан билгеләнә».